| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР<br>422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ<br>422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15 |

РЕШЕНИЕ КАРАР

4 декабрь, 2024 ел № 36

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 1 өлешендә:

түбәндәге эчтәлектәге 20 нче пунктны өстәргә:

«20) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру;»

28 пунктта «җирлек территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны төзү, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 39 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 1.9 пунктын өстәргә:

«9.1) аның тарафыннан чит ил агенты статусын алу;»

1.3. 48 статьяның 1 өлешендәге 13 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыра»;

1.4. 73 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 нче өлешне өстәргә:

«3. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасына электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев